КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 29 декабрь г.Казань № 1723

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2022 ел, 21 сентябрь, 1026 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2022 ел, 21 сентябрь, 1026 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 28 март, 365 нче; 2023 ел, 3 июль, 777 нче; 2023 ел, 28 сентябрь, 1194 нче; 2023 ел, 3 ноябрь, 1417 нче; 2023 ел, 8 декабрь, 1572 нче; 2023 ел, 23 декабрь, 1674 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2023 елга социаль-көнкүреш хезмәтләре, социаль-медицина хезмәтләре, социаль-психологик хезмәтләр, социаль-педагогик хезмәтләр, социаль-хезмәт хезмәтләре, социаль-хокукый хезмәтләр, социаль хезмәтләрдән файдаланучыларның коммуникатив потенциалын арттыру максатларындагы хезмәтләр, ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтүне кертеп, стационар һәм ярымстационар формада социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнарда:

I бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «6. | Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәгенең наркомания белән авыручыларны социаль тернәкләндерү бүлеге | - | - | 589,13 | - |
| 6.1. | социаль һәм көнкүреш хезмәтләре күрсәтү | - | - | 30,54 | - |
| 6.2. | социаль-психологик хезмәтләр күрсәтү | - | - | 57,31 | - |
| 6.3. | социаль-педагогик хезмәтләр күрсәтү | - | - | 283,76 | - |
| 6.4. | социаль һәм эш хезмәтләре күрсәтү | - | - | 160,21 | - |
| 6.5. | социаль-хокукый хезмәтләр күрсәтү | - | - | 57,31 | -»; |

II бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «6. | Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәгенең наркомания белән авыручыларны социаль тернәкләндерү бүлеге | 137,87 | 125,64 | 12,23»; |

әлеге карар белән расланган 2023 елга дәүләт хезмәте күрсәтүгә гомумхуҗалык ихтыяҗларына норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентларына түбәндәге эчтәлекле 9 пункт өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «9. | Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәгенең наркомания белән авыручыларны социаль тернәкләндерү бүлеге | |
| 9.1. | «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Әлмәт муниципаль районындагы «Опека» ХСХККҮ» СХКДАУнең наркомания белән авыручыларны социаль тернәкләндерү бүлеге | 0,20 |
| 9.2. | «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Яр Чаллы шәһәре» шәһәр округындагы «Доверие» ХСХККҮ» СХКДАУнең наркомания белән авыручыларны социаль тернәкләндерү бүлеге | 0,21 |
| 9.3. | «Казан шәһәре» шәһәр округында ХСХККҮ» СХКДАУнең наркомания белән авыручыларны социаль тернәкләндерү бүлеге | 0,50»; |

әлеге карар белән расланган 2023 елга стационар һәм ярымстационар социаль хезмәт күрсәтү формаларындагы дәүләт оешмаларында ятак-көннәр һәм ятак-урыннар санында:

«Әлмәт муниципаль районы» юлына түбәндәге эчтәлекле өстәмә юл өстәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Әлмәт муниципаль районындагы «Опе- | - | 1 620 | - | - | 20 | -»; |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | ка» ХСХККҮ» СХКДАУнең наркомания белән авыручы-ларны социаль тернәкләндерү бүлеге | | | | | | |

«Яр Чаллы шәһәре» юлына түбәндәге эчтәлекле өстәмә юл өстәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Яр Чаллы шәһәре» шәһәр округындагы «Доверие» ХСХККҮ» СХКДАУнең наркомания белән авыручыларны социаль тернәкләндерү бүлеге | - | 1 640 | - | - | 20 | -»; |

«Казан шәһәре» юлына түбәндәге эчтәлекле өстәмә юл өстәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | «Казан шәһәре» шәһәр округында ХСХККҮ» СХКДАУнең наркомания белән авыручыларны социаль тернәкләндерү бүлеге | - | 1 700 | - | - | 20 | -». |

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

бу карарның гамәле 2023 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла;

бу карар 2023 елның 31 декабренә кадәр (31 декабрьне кертеп) гамәлдә була.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин